СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРЖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2018ел, 17 октябрь Әгерже шәһәре № 30-3

Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү (күмү) һәм эшкәртүне оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Җитештерү һәм куллану калдыклары Турында" Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 31 декабрендәге 503-ФЗ номерлы Федераль закон,"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы Советының 2012 елның 19 декабрендәге 20-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү (күмү) һәм эшкәртүне оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
- 1 бүлекнең 6 пунктындагы 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"калдыкларны җыю - аларны алга таба эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, аларны эшкәртүне, утильләштерүне, зарарсызландыру, урнаштыру максатларында калдыкларны кабул итү, урнаштыру;"
- 1 бүлекнең 6 пунктындагы 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::
"калдыкларны туплау-аларны алга таба эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру максатларында унбер айдан да артык вакыт эчендә калдыкларны туплау;"
2. Әлеге карарны PRAVO.TATARSTAN.RU Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына һәм agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерже муниципаль районы сайтына урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының сәнәгать, төзелеш, транспорт, элемтә һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе В.В. МАКАРОВ